ТЕЛ БӘЯСЕ
Дәүләт Советында милли мәгариф турында сөйләштеләр
> 2

БУТАЛГАН СУКМАК
Авыр хәлдә калган өлкәннәргә ничек ярдәм итәргә?
> 3

ИЗГЕ ЭШТӘ
Йөзьяшәр Асия Максютова 55 ел гомерен кешеләргә ярдәм итүгә багышлый
> 3

БӘХЕТЛЕ ТӘХЕТ
«ВТ»ның Татарстанда яшәүче милләтләр турында махсус проекты
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 129 (29096) | Чәршәмбе | 6 сентябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

КЫРЛАРЫННАН КҮРЕНЕР

УРЫП-ҖЫЮ ЭШЛӘРЕНЕҢ БЕРЕНЧЕЛ НӘТИҖӘЛӘРЕ БИЛГЕЛЕ

Уңыш – 2023

1,417 млн гектар җир. Республикада әнә шулкадәр мәйданда урып-җыю эшләре төгәлләнгән. Аграрийлар 3 млн 622 млн тонна уңыш җыеп алган. Тагын 25 мең гектар мәйданда эш көтә. Быелгы урып-җыю кампаниясенең сөендерерлек һәм көендерерлек сәбәпләре нинди?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Нәтиҗә ясар чак

Быел Кайбыч районы гомуми уңыш буенча – беренче унлыкка, бер гектардан уртача уңыш буенча беренче бишлеккә керә. «ВТ» хәбәрчесе элемтәгә кергән көнне Кайбыч кырларында урып-җыю эшләренә нокта куйганнар иде инде. Район башлыгы Альберт Рәхмәтуллин уңай үзгәрешләрнең сәбәпләрен менә нәрсәдә күрә:

– «Август – Кайбыч» җәмгыяте («Август – Агро»га керә. – **Авт.**) кергәннән бирле, авыл хуҗалыгы тармагында уңай динамика күзәтелә. Алар 5 млрд сумга якын инвестиция кертте. Техниканы яңарттылар. Район кырларының 75 проценты – алар карамагында. Яңа техника, яңа технологияләр кулланып, чиста итеп эшлиләр. Бөтен җирләрендә тәртип. Тукландыру эшен яхшы алып бардылар. Кырларга 200 кг тирәсе ашлама керттеләр. Бөтен кешене дә кызыксындырган хезмәт хакы күләме дә югары бездә. Хәзерге вакытта ул 50 мең сумны тәшкил итә, – дип сөйләде район җитәкчесе. – Корылык булса да, минемчә, башка районнар белән чагыштырганда бездә хәлләр начар түгел. Чәчүдән соң да яңгыр явып алды, июнь аенда көтелгән явым-төшемнәр булды. Шулар тәэсир итте. Аннан, быел күмәк хуҗалыклар нәтиҗәле эшләде. Уңай нәтиҗә – шушылай күмәк эшләүнең җимеше.

Альберт Рәхмәтуллин сүзләренчә, районда 2017 елда 100 мең тонна ашлык суктырган булганнар. Быел кыр эшләрен 107 мең тонна ашлык белән тәмамлыйлар. «Хәзер көзге чәчү эшләре бара. Анысын да берничә көндә бетерербез дип уйлыйм», – дип өметләнә ул.

Республика кырларыннан җыеп алынган уңышның гомуми күрсәткеченә иң зур өлеш керткән районнар арасында Тәтеш (168 мең т), Буа (159 мең т), Арча (154 мең т) да бар.

Арчада 62 мең гектарда урып-җыю эшләре башкарылган. Шуларның 50 меңнән артыгы бөртеклеләргә дигән мәйдан. Арча районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе Ленар Абдуллин сүзләренчә, бөртеклеләрне җыеп бетергәннәр. «Быел уңыш узган елгы күрсәткечтән кимрәк булды. Елына күрә начар димәс идем. Быелтыр без 220 мең тонна ашлык җыйган идек. Хәзер техник культураларны суктыру бара. Без – республикада иң зур бәрәңге мәйданнары булган район. Бәрәңге алуга керештек. Ничек кенә булса да, чәчкәнне җыеп алырга да кирәк. Кырда эшләүчеләр дә яхшыга өмет итеп эшләде. Тик җитештергән продукциянең бәясе булмау гына күңелне тырнап тора», – диде ул.

Уңыш алуда иң яхшы 5 район (ц/га)

Тәтеш	39,2
Чүпрәле	37,8
Кукмара	35,7
Кама Тамагы	35,3
Кайбыч	34,4

Уңыш алуда артта калган 5 район (ц/га)

Чирмешән	17,1
Әлмәт	16,2
Азнакай	15,8
Баулы	15,3
Ютазы	15,1

Сөенечләр һәм уңыш

Ничек кенә булмасын, кыр уңганнарын дәүләт тә ярдәменнән ташламаска тырыша. Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров сүзләренчә, бюджет чикләүләренә карамастан, федераль һәм республика казнасыннан тармакка күрсәтелә торган матди ярдәм чараларын саклап кала алганнар. Барлыгы 14,1 млрд сум акча бүлеп бирелгән (федераль бюджеттан – 3,4 млрд, республика бюджетыннан – 10,7 млрд сум).

Уңышның нинди буласына техника һәм технологияләр куллану да йогынты ясый. Министр әйтүенчә, Татарстанда машина-трактор паркын яңарту дәвам итә. Әйтик, агымдагы елда аграрийлар 2,1 мең берәмлек яңа техника сатып алган: 294 трактор, 177 комбайн, 1,6 мең берәмлек башка төр техника. Быелтыр исә 3,1 мең берәмлек техника һәм кирәк-ярак сатып алган булганнар.

Көенечләр һәм ярдәм

Марат Җәббаров әйтүенчә, кайбер тискәре күренешләрнең сәбәбе – көтелмәгән суыклар һәм көттергән яңгырлар.

– Иң төп сәбәп – һава торышы, билгеле. Яңгырлар яумады. Чәчү иртәрәк башланды, кисәк суытты. Татарстанның көнчыгыш өлешендә явым-төшемнәр норманың 45 процентын гына тәшкил итте. 30 мең га җирне яңадан чәчәргә туры килде. Корылык та үзен күрсәтте, – диде министр.

Ахыры 2 нче биттә >

Чир китми

Россиядә ковид йоктыручылар саны арта. Узган атнада әлеге күрсәткеч 31,6 процентка үскән. Коронавирус инфекциясенә каршы көрәш буенча оператив штаб хәбәренә караганда, хастаханәгә салу очраклары да алдагы атнадагыга караганда 13,2 процентка күбәйгән. 1172 кешене хастаханәгә салганнар.

Шул ук вакытта бер атна эчендә 3655 кеше савыккан. Алдагы атнадагыга караганда 17,8 процентка зуррак сан бу.

Исегезгә төшерәбез: июльдә Роспотребнадзор башлыгы Анна Попова көзен коронавирусның көчәюе көтелү турында хәбәр иткән иде. Ведомствоның Татарстан буенча идарәсе башлыгы урынбасары Любовь Авдонина да, ОРВИ сезоны башлану сәбәпле, шундый ук фаразын җиткерде. Сүз уңаеннан, республикада коронавирусның үпкә ялкынсынуы китереп чыгару очраклары күбәйгән.

Бөтен хастаханә – бер номерда

4 сентябрьдән Татарстан сәламәтлек саклау өлкәсенең бердәм элемтә үзәге тест режимында эшли башлады. «Кайнар линия», республиканың барлык медицина оешмаларын бер урынга берләштереп, тәүлек әйләнәсе эшләячәк.

Элемтә үзәге барлык мөрәҗәгатьләрне тиз генә карау мөмкинлеге бирә. Сервис медицина оешмаларына телефон аша «барып җитү»гә ярдәм итәчәк, сәламәтлек саклау өлкәсенә җәмәгать контролен булдырачак.

Шулай итеп, «кайнар линия» номерына (558-03-03) шалтыратып, медицина ярдәме күрсәтү һәм оештыруга бәйле барлык сорауларга җавап табып булачак. Аның аша, әйтик, сырхауханәгә беркетелү, ташламалы дарулар, югары технологияле медицина ярдәме алу, дәвалануның сыйфаты кебек мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Операторлар мәгълүмат системасында электрон медицина карталары буенча сырхауларга медицина ярдәме күрсәтүнең эзлеклелеген күзәтеп тора алачак.

Бердәм элемтә үзәгенең хастаханә, сырхауханәләр эшенең «үтәкүренмәлелеген», республикада яшәүчеләрнең медицина оешмалары белән элемтәсен булдыруы, медицина ярдәменең нәтиҗәсен арттыруы күздә тотыла.

Беркатлы мөгаллимнәр

Татарстанда бер тәүлек эчендә дүрт хатын-кыз-педагог – 2 балалар бакчасы тәрбиячесе, Казан мәктәбе укытучысы һәм университет мөгаллиме мошенниклар корбанына әйләнгән. Алар аферистларга барлыгы 4 миллион сумнан артыграк акча биргән.

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгыннан хәбәр итүләренчә, Казан мәктәбе укытучысы – 52 яшьлек ханым, үз исеменә кемнәрнеңдер кредит алуыннан куркып, банкомат аша мошенникларга 1,3 миллион сум акча җибәргән. Шулай ук Казаннан 68 яшьлек университет укытучысы, «Ватсап» аша шалтыраткан «банк хезмәткәрләре»нең тасма теленә ышанып, акчасын «имин» счетка күчереп куйган. Лениногорскида яшәүче 52 яшьлек тәрбияче ханымга исә финанс платформасында акча эшләү тәкъдим ителгән. Монысы ниндидер ике номерга 700 мең сум юллап, акчасыннан коры калган.

Чистайдан 56 яшьлек балалар бакчасы тәрбиячесе дә аферистлар «кармагы»на эләккән. Аны картасыннан акча урлау белән куркытканнар. Тәрбияче шундук якындагы банкоматка барып, мошенниклар күрсәткән счетка 1,3 миллион сумнан артыграк акчасын күчергән.

Икътисад

Тәгәрмәчле бурыч

629 миллиард сум. Быелның җиде аенда илдә яшәүчеләр әнә шулкадәр автомобиль кредиты җыйган. Машинада йөрим дип, халыкның бу кадәр бурычка батканы юк иде әле, дип чаң суга белгечләр.

Кредит тарихлары илкүләм бюросы мәгълүматларына караганда, бу елның җиде аенда россиялеләр 628,9 миллиард сумлык автокредит рәсмиләштергән. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, бурычлы «тимер ат» хуҗалары 71,5 процентка күбрәк. Кемнәрнең әҗәт капчыгы зуррак икәне дә билгеле. Беренче урында – Мәскәү өлкәсендә яшәүчеләр. Алар 44 миллиард сумлык автокредит рәсмиләштергән. Санкт-Петербург халкының банкларга машина өчен 38 миллиард сумлык бурычы бар. Беренче өчлеккә Татарстан һәм Краснодар крае да эләккән. Аларның һәркайсы 29 миллиард сумлык автокредит алган.

– Халык, дәррәү кубып, кредитка автомобиль сатып ала башлаган дип уйламыйм, – ди икътисад белгече Илдус Сафиуллин. – Узган ел башында чит ил брендлары илдән киткәч, автомобиль базары бер мәлгә тынып калды. Арзан машиналарны алып бетерделәр, ә яңалары кыйммәт бәядән кайта башлады. Мондый шартларда илдә яшәүчеләр автомобиль сатып алуны кичектереп торуны артыграк күрде. Бүген исә без базарның кабат җанлануын күрәбез. Ни генә булмасын, машинада йөрергә өйрәнгән кеше аннан баш тартмаячак. Кредит хисабына булса да. Халыкның керем дәрәҗәсе әллә ни артмады. Чыгымнар бер яктан күбәеп китсә, аларны икенче яктан кысарга туры киләчәк, димәк.

«Россия автомобиль дилерлары» ассоциациясе мәгълүматларына караганда, быел Россиядә яңа җиңел машинаның уртача бәясе 2,6 миллион сумга җиткән. Узган ел белән чагыштырганда, әлеге күрсәткеч 20 процентка арткан. Август башында гына да илдәге унбишләп автомобиль бренды бәяләрне күтәрү турында игълан итте. Сәбәпләре дә билгеле. Беренчедән, сум очсызланса, икенчедән, 1 августтан илдә утильләштерү җыемы, ягъни илгә читтән сату өчен кертелүче җиңел, коммерцияле автомобильләр, йөк машиналары һәм автобусларга бер тапкыр түләнә торган салым артты.

– Яңа машинада йөрергә теләүчеләр автомобиль базарында тотрыклылык урнашканны көтеп арыган, күрәсең, – ди Россия автомобильчеләр федерациясенең Татарстандагы җитәкчесе Рамил Хәйруллин. – Аңлавымча, автокредитлар күләме Кытай машиналары хисабына арткан. Бәлки, халык илдән киткән брендларның кире кайтуын көткәндер. Булмагач, ни бар, шуны алырга керешкәннәр. Өстәвенә автомобиль сатып алуны кичектерүдән файда юк. Машина бәяләре көннән-көн арта. Әлеге дә баягы шул Кытай автомобиленә күчеп утырсаң гына инде. Илдә җитештерелгән автомобильләргә килгәндә, аларның сыйфаты бәясенә туры килми дип саныйм. Әнә ил базарына якын арада ук Иран автомобильләре керәчәк дип фаразлыйлар. Бәлки, алар көндәшлекне арттырыр. Шунысын да истән чыгармаска кирәк: яңа машиналар базары артыннан иске автомобильләр базары да кабат үсә башлаячак. Кеше буяу исе дә кипмәгән «тимер ат» сатып ала икән, димәк, булганын сатачак. Элек рульдә йөрүчеләр, гадәттә, биш елга бер тапкыр машина алмаштырса, хәзер әлеге күрсәткеч 7–8 елга кадәр җитте. Чөнки яңа автомобильләр бик кыйммәт. Бүген 1 миллион сумга яңа машина сатып алып булмый. Бердәнбер чыгу юлы – автокредит.

Сүзгә-сүз

Андрей КАРТАПОЛОВ, РФ Дәүләт Думасының Оборона буенча комитет рәисе:

РФ Оборона министрлыгының өстәмә мобилизация уздыруы турында интернетта таралган хәбәрләр дөрес түгел. Безнең дошманнар социаль челтәрләрдә тараткан ялган документ ул. Шуңа күрә мондый хәбәрләргә игътибар да итәсе түгел. Хәзерге вакытта өстәмә мобилизация уздыруга ихтыяҗ юк. Актив рәвештә контракт буенча хезмәткә җыю дәвам итә.

(ТАСС)

ИДЕЛ БУЕ ТӨБӘКЛӘРЕНДӘ – АЗЫК-ТӨЛЕК БӘЯСЕ

Белгечләр Идел буе федераль округы төбәкләрендә минималь азык-төлек җыелмасының июль аендагы бәясен исәпләп чыгарган.

Төбәк	Бәя, сумнарда
Мордовия Республикасы	5135,43
Пенза өлкәсе	5175,09
Саратов өлкәсе	5258,52
Татарстан Республикасы	5303,13
Башкортстан Республикасы	5581,85
Оренбург өлкәсе	5670,70
Пермь крае	6014,18
Округ буенча	**5474,51**
Россия буенча	**6033,30**

Ярминкәгә килегез!

Шимбә – 9 сентябрьдә Татарстанда авыл хуҗалыгы ярминкәләре башлана. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров әйтүенчә, андагы бәяләр, продукция төренә карап, кибетләрдәге уртача бәядән 4–50 процентка арзанрак булачак. Ярминкәләр Казанда – 14 мәйданчыкта, шулай ук Чаллы һәм Яшел Үзән районнарында – икешәр, Түбән Камада – өч мәйданчыкта һәм 14 районда үткәреләчәк.

Ярминкәгә азык-төлекне районнарның авыл хуҗалыгы сәнәгате оешмалары китерәчәк. Сәүдә 23 декабрьгә кадәр һәр атна саен гөрләячәк.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КОРАЛ ЭЗЛӘП МИСЫРГА

Соңгы көннәрдә Көнбатыш сәясәтен билгеләүче эре чиновниклар глобаль көньяк илләренә визитларын ешайттылар. Италиянең тышкы эшләр министры Кытайга визиты алдыннан максатларының берсе Украинадагы конфликтны көйләү икәнен белдерде. АКШның сәүдә министры Джина Раймондоның да Кытайга дүрт көнлек визиты төгәлләнде. Очрашулар зур нәтиҗә бирмәгәндер, күрәсең, «вазгыятьне аек» бәяләвен, Пекинга бәйле проблемаларның «бер сәгатьтә генә хәл ителерлек түгел»леген әйтте.

АКШның сәясәт карчыгалары, Россиягә каршы санкцияләргә кушылмаган илләргә басым ясап, аларны Мәскәү белән хезмәттәшлектән тыярга омтылалар. Үткән тәүлекләрдә Берләшкән Гарәп Әмирлекләре Вашингтонның нык кисәтүенә дучар булды. АКШ гарәпләрне Россиягә тыелган товарлар озатуда гаепли, санкцияләргә кушылырга чакыра.

Мисыр Президенты Сиси америкалылар делегациясен кабул итте. Делегациядә Россиягә каршы аяусыз көрәш алып баручы сенатор Линдси Грэм да бар. Сиси элегрәк Россиягә корал сатуда гаепләнеп, кисәтү алган иде инде. Ул гаепне төзәтүе турында акланып та өлгермәде, Украинага ярдәм итәргә күрсәтмә алды. Әмма Каһирәдә океан артыннан килгән күрсәтмәне үтәргә ашыкмадылар. Сенаторлар делегациясе сәяси һәм икътисадый проблемаларның киң спектры хакында әңгәмә алып барды. Әмма төп тема корал мәсьәләсе булды. Мисырны Украинага корал һәм сугыш кирәк-яраклары сатарга күндерү максатыннан америкаларнар аңа кайбер өстенлекләр вәгъдә итә. Әйтик, күрше илләр – Судан һәм Эфиопия белән бәхәсләрдә Каһирә ягын каерырга җыеналар. Моңа җавап итеп, Мисыр Киевка корал озатырга тиеш. Чүл өстендә урнашкан гарәп дәүләте залп уты ачучы ракета системалары ягыннан дөньяда алтынчы урында, танклар саны буенча бишенче урында тора икән. Искерәк булса да, шул коралларны Украинага озатса, Мисыр көнбатышлыларның җылы карашын тоячак. Әлегә кадәр Каһирә бу мәсьәләдә нейтралитет сакларга тырышты. 2022 елның 4 мартында Мисыр делегациясе БМОда Россияне гаепләп тавыш биргән иде.

Көнбатыш заводлары Украинага кирәкле күләмдә снарядлар һәм ракеталар ясап өлгерә алмый. Хәрби-сәнәгать комплексы бик зур табыш ала, билгеле. АКШ полковнигы Лоуренс Уилкерсон «Ютуб» каналларының берсенә биргән әңгәмәдә: «Сугыш – гаҗәп гүзәл нәрсә! Россия никадәр күбрәк украин истребительләрен бәреп төшерсә, Американың хәрби-сәнәгать комплексы шулкадәр күбрәк заказ алачак», – диде.

Россиядә

СӨЙЛӘШҮ – БАР, КИЛЕШҮ – ЮК

Россия һәм Төркия лидерларының Сочидагы очрашуы дөньякүләм игътибар үзәгендә булды. Сөйләшүдә бик аз дигәндә «ашлык килешүе» төзелер һәм Украина кораблары, ашлык төяп, Кара диңгез аша сәүдә юлына чыгарлар дип көтелгән иде. Очрашуның алдан әзерләнүе, ике ил дипломатларының берничә тапкыр күрешүе инде әзер документларга имза гына салыныр дигән өметне үстерде. Кара диңгез аша үтү соңгы вакытларда Россия корабларына да кыенлашканга күрә, Мәскәү дә Әнкара тәкъдимнәренә каршы килмәс дип уйладылар. Италиянең тышкы эшләр министры Әрдоганны Путинны «ашлык килешүе»н имзаларга күндерә алырлык бердәнбер шәхес дип бәяләве башка илләрдә дә ике яклы саммитның уңышлы булуын көтүләрен дәлилли иде.

Лидерларның күрешүе бик югары дәрәҗәдә оештырылды. Монысы да яхшы фал иде. Очрашуда «ашлык килешүе» генә түгел, ике яклы башка бик күп хезмәттәшлек мәсьәләләре дә каралганлыктан, аның бер имзасыз төгәлләнүе гаҗәпкә калдырды. Ә бит Украина белән тыныч килешүнең контурлары да шул очрашуда шәйләнә башламасмы икән дигән тычкан уты күләмендә генә булса да өмет юк түгел иде. Барлык көткәннәрнең дә кысыр булып чыгуы мәгълүмат чараларына очрашу нәтиҗәсез төгәлләнде дип игълан итәргә юл ачты. Әмма эш без уйлаганга караганда катлаулырак булырга охшаган. Очрашу башында Әрдоган гаҗәпкә калды, әлбәттә, чөнки Путин бөтенләй көтелмәгән тәкъдимнәр белән чыкты. Ул нинди яңа тәкъдимнәр тартып чыгарды – без белмибез. Бер нәрсәне әйтә алабыз: Путинның көтелмәгән тәкъдимнәре Әрдоганны кызыксындырган булырга тиеш, чөнки очрашудан соң социаль челтәрдә Путинны «кадерле дус» дип атаган пост урнаштырды. Төрек Президентының ачуланып кайтып китмәве үзе генә дә уңыш ул, чөнки Әнкара Кремль ашына таракан булып төшәрлек байтак гамәлләр кыла ала. Ул гамәлләр кылынмаячак. Төрле аналитикларның бу очрашу хакында киң фаразлары бар. Автор, мөгаен, шуларны туплап зуррак язма әзерләр.

Россиягә Төркия арадашчылыгында санкцияләр боҗрасыннан чыгу бик мөһим. Бу юллар язылганда, доллар курсы яңадан 97ле чикне узды. Сумның зәгыйфьләнүе нефтькә бәяләр күтәрелү фонында бара. Бу – Россия икътисадында структур проблемалар бар һәм алар үсә дигән сүз. Бензинга бәяләр күтәрелә һәм аның дефициты да тукталмый. Төркия бүген Россия өчен Европага тәрәзә ролен үти. Шулай булгач, Сочи очрашуы эзсез үтмәгәндер дип өметләник.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

БЕЛЕМ ТӘҖРИБӘДӘН ТУА

Татарстанның әйдәп баручы фәнни белем бирү оешмалары илнең фәнни-технологик үсешенә бәйле барлык стратегик тәкъдимнәрдә катнаша. Бу хакта Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов «Планетаның сыек углеводородлар запасларын нәтиҗәле үзләштерү» дөнья дәрәҗәсендәге фәнни үзәкнең халыкара күзәтүчеләр советы утырышында әйтте.

Чара КФУның фәнни китапханәсе бинасында узды. Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, бүген республикадагы биш вуз «Приоритет 2030» стратегик академик лидерлык программасында катнаша. Өч алдынгы инженерлык мәктәбе, ике махсуслашкан уку-фән үзәге, инжиниринг үзәге, шулай ук тармакара технологияләр трансферы үзәге гамәлдә. Моннан тыш, былтыр «Университет технологик эшкуарлыгы платформасы»нда республика стартап студиясе эшли башлады, студентлар стартаплары бәйгесе нәтиҗәсендә 371 университет кече бизнесы оешты.

– Алдынгы тикшеренү һәм инновацион инфраструктура объектлары арасында федераль университетның дөнья дәрәҗәсендәге фәнни үзәге аерым урын алып тора. Аның эшчәнлеге әле озак вакыт Татарстанның төп икътисадый үсеш шартын тәшкил итәчәк республика минераль-чимал базасын экологик яктан куркынычсыз тулыландыруга юнәлдерелгән, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Рәис искәртеп узганча, Үзәк эшчәнлегеге ярдәме белән дүрт елда тикшеренүләр һәм эшләнмәләр тармагына федераль бюджеттан 1 миллиард сумга якын акча җәлеп ителгән.

tatarstan.ru

– Субсидия алучылар үзләренә үсеш программаларын тормышка ашыру һәм тәгаен нәтиҗәләргә ирешүгә бәйле җитди җаваплылык алуын да истән чыгарырга ярамый. Шуңа күрә моңа кадәр узган очрашуда күзәтүчеләр советы утырышын елга кимендә өч тапкыр үткәрү карарын кабул иттек. Бу үзәк эшчәнлеге нәтиҗәләрен оператив рәвештә бәяләргә һәм тиз арада чаралар күрергә ярдәм итәчәк, – диде Рәис.

КФУ ректоры Ленар Сафин сүзләренә караганда, дөнья дәрәҗәсендәге «Планетаның сыек углеводородлар запасларын нәтиҗәле үзләштерү» фәнни үзәге өч нефть университеты – Уфа дәүләт нефть-техник университеты, И.М. Губкин исемендәге Россия дәүләт нефть һәм газ университеты һәм Сколково фән һәм технологияләр институты белән берлектә эшли.

Фәнни үзәкнең агымдагы елда ирешкән нәтиҗәләре белән КФУ проректоры Данис Нургалиев таныштырды. Аның әйтүенчә, бүген үзәк Россиядәге генә түгел, ә чит илләрдәге эре нефть һәм газ чыгаручы һәм сервис компанияләре белән уңышлы эшли.

– Барлык эшләнмәләрне алар белән берлектә сынап карыйбыз һәм кулланышка кертәбез. Безнең партнерлар исемлегендә Россия, Куба, Кытай, Вьетнам, Һиндстан, Кувейт, Оман һәм башка илләрдәге зур компанияләр бар, – диде Данис Нургалиев.

Быел фәнни үзәк консорциумы 160тан артык проект башкарган. Аларның гомуми бәясе 1 миллиард сумнан да артып киткән. Биредә белем бирү программаларын үстерүгә дә зур игътибар бирәләр.

– Безнең студентларның өчтән бере диярлек – 60ка якын ил гражданнары. Аларны Россиядә генә укытмыйбыз. Безнең сигез халыкара магистратура, унга якын аспирант программасы гамәлдә. Бу елның көзеннән Кытай университетлары белән дә үзара алмашу программалары эшли башлады, – дип тә өстәде Данис Нургалиев.

Милли мәгариф

КАЙДА БЕЗНЕҢ СЫЙНЫФ?

Яңа мәктәпләр ачыла, ә татар сыйныфлары кайда? Татарстан Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре буенча комиссия рәисе Марат Әхмәтов әнә шундый сорау бирде. Ул министрлыкка бу мәсьәләгә карата игътибарны көчәйтергә киңәш итте.

Министр урынбасары Алсу Әсадуллина узган ел республикада тормышка ашырылган программалар турында сөйләде. Шулай ук быел мәктәп-бакчаларга кертелгән яңалыклар белән таныштырды. Арада бердәм дәреслекләр, программаларга кагылышлысы да бар. Урынбасар тәрбия эшенә игътибар бирелүен дә билгеләп үтте. Ятимнәр темасы да читтә калмады. Узган ел 600 фатир бирелсә, быел бу санны 900дән арттырмакчылар.

Депутатлар арасында яңа мәктәпләргә укытучыларны ничек җәлеп итәргә җыенулары турында сораучылар да булды. «Башка төбәкләрдән укытучыларны китерү, тулай тораклар төзү каралмаганмы?» – дип тә сорадылар.

– Кадрлар кытлыгы бакчадан ук башлана. Укытучыларны җәлеп итү проблемасы бар. Быел педагогия уку йортларын тәмамлаган физика, математика укытучыларының барысы да мәктәпкә барган очракта да кытлыкны япмый, – диде Алсу Әсадуллина. Ә укытучыларга тулай тораклар төзү тәкъдимен хуплады.

Марат Әхмәтов исә Алсу Әсадуллина чыгышында республикада мәгариф тармагына шактый акча бүленеп бирелүен, әмма мәгарифнең моңа ничек җавап бирүе, сыйфат ягы турында мәгълүмат җитеп бетмәвен әйтте. Чыгышны тулыландырырга кирәк, диде.

– Мине милли мәгариф мәсьәләсе борчый. Министрлыкның битараф түгел икәнлеген беләм. Туган телне мәҗбүри укытып булмый. Әмма министрлыкны, мәктәпләрдә милли мәгариф эше аксый, дип тәнкыйтьләүчеләр дә бар. Милли мәгарифкә ихтыяҗ булсын өчен милли мохит булырга тиеш, – диде Марат Әхмәтов. – Мәктәпләрдә, уку йортларында милли мәгарифнең торышы мәктәпнең эшчәнлегенә бәя куймый. Чөнки татар теле һәм әдәбиятыннан бердәм республика имтиханын тапшырмасаң да була. Бу сынауны сайлаучылар аз. Быел аны 8 укучы бирде. Узган ел берәү генә иде. Мәктәп директоры, мәгариф бүлекләре, методик үзәкләр, Мәгарифне үстерү институты мәктәпләрдәге милли эчтәлеккә контрольне көчәйтсен иде.

Мәктәп директоры, урынбасарлар, методистлар ничә тапкыр татар теле дәресенә кереп карады икән? Методик үзәктә эшләүче белгечләр дәресләрдә ни дәрәҗәдә актив катнаша? Менә шундый сорауларны да бирде Марат Әхмәтов.

Үзенең укытучы малае икәнлеген дә искә төшерде. Ул, әти-әнисенең, мәгариф бүлегеннән инспектор килеп, дәрескә керә, ачык дәрес бирәсе бар, дип әзерләнгәнен хәтерли.

– Бүген татар теле һәм әдәбияты дәресләренә беркем дә керми, диләр. «Синең хезмәтең кемгә кирәк?» – дигән сорау туа. Әгәр беркемгә дә кирәк түгел икән, хезмәтемә мөнәсәбәтем дә шуңа тиңдәш булачак. Үзәктән эчке контрольне көчәйтсеннәр иде, – диде ул.

Ул шулай ук милли мәктәпләрнең узган гасырның туксанынчы елларында милли күтәрелеш чорында оешуын әйтте. Болар – 70–80 нче елларда ук төзелгән биналар. Марат Әхмәтов фикеренчә, алар заман мәктәбе белән көндәш була алмый.

«Татар-информ»

– Республикада быел 11 яңа мәктәп ачылса, шунда ничә татар сыйныфы ачылды икән? 2019, 2020, 2021 елларда Казан, Чаллыда төзелгән яңа мәктәпләрдә («Адымнар»ны санамасак) бары бер генә татар сыйныфы оешкан. Сүз 1 нче сыйныфларга укучылар кабул итү турында бара. Бу мәсьәләгә дә игътибарны арттырырга кирәк. «Тел кемгә кирәк ул?» – дигән сәбәп табып, бу мәсьәләдә качып йөрергә ярамый. Әти-әни өчен мәктәп сайлаганда уку йортының җиһазландырылган булуы да мөһим. Әгәр «Ф» сыйныфына кадәр укучылар туплап, бер татар сыйныфы да ачылмаган икән, моңа риза булырга ярамый, – диде ул.

Сәрия МИФТАХОВА

КЫРЛАРЫННАН КҮРЕНЕР

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Быел Татарстанда бөртеклеләрне сатып алу бәясе түбән тәгәрәде. Әйтик, арыш – 22, арпа – 17, бодай 3–9 процентка арзангарак сатыла. Моңа узган елгы рекордлы уңыштан соң барлыкка килгән ашлык запасы сәбәпче. Хәзерге көндә республикада узган елдан калган 600 мең тонна уңыш саклана.

Җитештерүчеләргә ярдәм итү максатыннан Россия Хөкүмәте сатылган ашлыкка чыгымнарны каплауга субсидия бүлеп бирә. Узган ел федераль бюджет акчасы хисабына 1,3 миллиард сумлык 990 мең тонна сатылган ашлык субсидияләнгән. Шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә өстәмә ярдәмне интервенция фондына (дәүләт запасы. – **Авт.**) ашлык сатып алу аша да күрсәтәләр. 2022 елда 226 мең тонна ашлык уртача бәядән югарырак бәягә сатып алынган. Агымдагы елда җитештерүчеләргә 718 миллион сум күләмендә дәүләт ярдәме күрсәтелгән, 446 мең тонна сатылган ашлык субсидияләнгән.

Бөртеклеләр экспорты: 12 млн доллар.
Кая сатыла: Иран, Сүрия, Төркия, Казахстан.

Урып-җыю эшләре тәмамлануга кырлар тынып кала дигән сүз түгел әле. Марат Җәббаров әйтүенчә, әле кукуруз, көнбагыш җыясы бар. Рапс, шикәр чөгендере, бәрәңге алу эшләрен төгәлләргә кирәк. Шикәрсез дә, «икенче икмәк»сез дә, яшелчәсез калмабыз, ди министр. Ач калырбыз дип куркасы түгел, кыскасы.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Республика буенча уңышның уртача күрсәткече

2020 ел – 35,3 ц/га
2021 ел – 15,4 ц/га
2022 ел – 36,9 ц/га
2023 ел – 25,8 ц/га

КОТЛЫЙБЫЗ!

Югары дәрәҗәдәге һөнәри осталыгы, республиканың дәүләт хакимияте органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсенең гомуми бүлеге беркетмә секторы I категорияле белгече **Шеронова** Эльмира Рөстәм кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Таттелеком» гавами акционер җәмгыяте хезмәткәрләре: генераль директорның операция эшчәнлеге һәм режим буенча урынбасары **Белобородов** Сергей Александровичка, Әлмәт электр элемтәсе зона узелының Мөслим район электр элемтәсе узелы сату офисы белгече **Заманова** Зөлфия Миргалим кызына, Буа электр элемтәсе зона узелының Кама Тамагы район электр элемтәсе узелы эксплуатация-техник төркеме инженеры **Хәйруллина** Мария Анатольевнага, Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекциясенең спирт, алкогольле һәм спиртлы продукция әйләнеше өлкәсендә хисаплылыкны контрольдә тоту бүлеге башлыгы **Сабун** Борис Григорьевичка, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгълүмат технологияләре һәм элемтә идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы урынбасары – мәгълүмат куркынычсызлыгы бүлеге башлыгы **Сапегин** Тимур Николаевичка **«Татарстан Республикасының атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Чаллы шәһәре буенча идарәсе полиция патруль-пост хезмәте аерым батальоны (массакүләм чаралар буенча) 5 ротасы мобиль взводы инспекторы (полиция патруль-пост хезмәте), полиция лейтенанты **Бартов** Денис Михайловичка, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе полиция патруль-пост хезмәте полкы 1 батальоны командиры, полиция подполковнигы **Крымов** Альберт Альфрит улына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы штабы башлыгы, эчке хезмәт полковнигы **Лопарев** Дмитрий Алексеевичка **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

«ҖИДЕ ЮЛ ЧАТЫНДА» НИЛӘР БАР?

ТНВ ЯҢА СЕЗОНДА ТАМАШАЧЫГА ЯҢА СЕРИАЛ ТӘКЪДИМ ИТӘЧӘК

Мамадыш трактында урнашкан «Татнефть» автоягулык салу станциясендә тулы бер гомер үтте: кешеләр кавыштылар да, аерылыштылар да, югалдылар да, табыштылар да. Биредә җәй буена сузылган «Җиде юл чатында» сериалын төшерү эшләре тәмамланды. 20 сериядән торган сериалның премьерасы ел ахырында көтелә.

tnv.ru

Ягулык салу станциясе – кешеләр язмышлары, юллар кисешә торган урын. Бирегә һәркем үз уйлары, проблемалары, дөньяга карашы белән килә һәм һәрберсе үз юлын табарга тели. «Ватан XXI гасыр» кинокомпаниясе төшергән сериал тамашачыларга бер ягулык салу станциясе кысасында барган вакыйгалар, тормыш хәлләре турында сөйләячәк.

– Сериалның исемен үзгәрттек. Җәй башында, беренче эпизодларны төшерә башлаганда, сериалга «Юллар чатында» дигән эш атамасы биргән идек. Йомгаклау эшенә килеп җитәрәк, бөтен атмосферасын, нечкәлекләрен, урынның үзенчәлекләрен исәпкә алып, «Җиде юл чатында» дип куярга булдык. Бер яктан бу барыбызга да яхшы таныш М7 трассасына бәйле. Безнең җәй буе эшләгән мәйдан үзе дә җиде юл чатында урнашкан. Монда тормыш ничек бара, нинди кешеләр килә, кемнәр туктый – барысын да төшереп бардык, – дип сөйләде журналистларга сценарий авторы Альберт Шакиров.

Аның сүзләренә караганда, төшергәндә тәҗрибә, тамашачы фикере дә истә тотылган. Әйтик, сериалны уртасыннан карый башласаң да, алдагы серияләрдә сүзнең нәрсә турында барганлыгын аңлап булачак.

– Бу беренче сериал гына түгел. Монысының төшерү процессы югары дәрәҗәдә оештырылганлыгы белән аерылып тора. Безнең команда яхшы эшли, аның төп өлеше үзгәрми. Шушы форматта кыска срокта сыйфатлы һәм күләмле проектлар эшли ала торган команда бар бүген. Барысы да – үзебезнең кешеләр, Аллага шөкер. Эшләр өчен мөмкинлекләр, процессны оештыру, команданы туплау осталыгы бар һәм югары дәрәҗәдә. Ул бик нык сизелә. Артистларны туплап, вакытында чакыру ягыннан да, сценарийга оператив рәвештә төзәтмәләр кертүдә дә. Җитештерү процессы тоткарланмый. Минем өчен бу иң мөһим әйбер. Гомумән, безнең өчен бу бик зур нәтиҗәле эш күрсәткече булып тора. Төп имтихан әле алда. Декабрь аенда тамашачыга барып җиткәч, алардан килгән фикерләрне дә исәпкә алачакбыз, – диде Альберт Шакиров.

Сериалны төшерү тәмамланса да, команда инде киләчәккә планнар кора. «Безнең хыялыбыз – елына бер генә түгел, ә күбрәк сериал төшерү һәм тулы метражлы нәфис фильмнар булдыру. Моның өчен мөмкинлекләр бар», – диде Альберт.

Режиссер Алмаз Әкбәров әйтүенчә, алар гади халык камераларга ничек карар икән дип борчылган. «Без барыннан да бигрәк «Мине төшермәгез, мине күрсәтмәгез» дигән агрессиядән курыктык. Бар да киресенчә булып чыкты: кешеләр махсус килде, без аларны эпизодик геройлар буларак төшердек», – диде ул.

«Тамашачы без төшергән сериалларны яратып карый һәм көтеп ала». «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директорының беренче урынбасары Илшат Сафиуллин шулай диде. Ул сериал төшерүдә ярдәм күрсәткән һәм урын тәкъдим иткәне өчен «Татнефть» хәйрия фонды җитәкчелегенә, Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе, шәхсән Марат Әхмәтовка рәхмәтен белдерде.

– Иң зур, иң катлаулы, чыгымлы һәм озын этап – төшерү эшләрен тәмамладык, хәзер монтажга күчәбез. Үзебез җитештергән сериаллар безнең тамашачылар өчен бик кирәк. Бу бик мөһим, чөнки кешеләр сатып алынган, тәрҗемә ителгән контенттан арыдылар инде, – диде Илшат Сафиуллин.

Ләйсән САФИНА

Мөнәсәбәт

Үтте җәйләр, җитте көзләр...

«Ни арада үтте бу җәй?!» Шушы вакытта авыл кешесе ел да кабатлый торган сүзләр бу. «Бигрәк тиз үтте, әле генә җәйгә кергән идек бит», – дигән кешеләргә мин быел: «Бу җәйне дә тиз үтте дисәгез, башка елга караганда бер айга озынрак булды бит, ул да җитмәдемени?» – дип аптыратам.

Кемнәрдер килешә, кемнәрдер – юк. Һәркем үз бизмәне белән үлчи. Язмышлар төрле, арабызда көне түгел, сәгате елларга тиң булып тоелган кешеләр дә бардыр, күңеле, җаны тыныч кешеләргә исә җәй ни, көз ни – барыбер.

Бүген бар табигатькә, бакчаларга иңгән көз төсе инде башка гамьнәр, мәшәкатьләр турында искәртә. Барысын да җыйнап аласы, тәртиплисе килә торган чорга кердек. Ничектер бу чорда бушаган түтәлләр дә үзенчә матур булып тоела. Бәрәңгеләре җыйнап алынган бакчалар да матур бу вакытта. Бу – эшләрне вакытында бетереп кую теләге генә түгел, «вакыты җиткән» дигәнне аңлатучы бер халәт тә, ахры. Агачларда да инде сары яфраклар күренә. Аларны да шул вакыты җиткәнгә юрыйбыз.

«Ни арада үтте бу җәй?!» – дигән кешеләрне дә аңлап була, миңа калса. Җәйне бит кара көздән көтә башлыйсың. Үзеңчә планнар корасың. Җәйгә чыгуга, кәефләр дә күтәрелеп китәр төсле тоела. Эшләрне дә җылы, кояшлы, эссе көннәрдә эшләү рәхәт булыр дип уйлыйсың. Тик җәйнең һәр көнендә 24 сәгать – тәүлек әйләнәсе эшләсәң дә, бетми торган эшләр бик тиз ардырта, җәйге эсселәр тиз туйдыра: кышкы салкыннар сагындыра башлый. «Салкын көннәрдә белеп зарланмаганбыз икән, ул чакта әле мичкә ягарга да, калын итеп киенергә дә була», – дип сөйләшәбез. Ни сәбәпледер, мондыйлар күп һәм эссе көннәрдән зарланмаучы сирәкләрне күреп, үзебезчә аптыраган да булабыз әле.

Иртә-кич салкынча булу, иртәнге томан, чык табигатьне дә, кешеләрне дә, көз җитте, дип кисәтә. Җилләре дә салкынча, көзгә тартым, ачык тәрәзәдән кергәне өйдәге һаваны алыштыра, сафландыра. Һәм табигатьтәге бар үзгәреш күңелгә көзге моңсулык өсти: чалт аяз күк йөзе дә, «бирешмим» дип тырышып җылытучы кояш та хәзер инде бөтенләй башкача. Бар табигать, җан ияләре күчеш этабына керде һәм шуның белән яши дә башлады. Көз бик якында, кул сузымында гына. Алтын көзләр барыбызны хисләндерсә, сөендерсә дә, бу матурлык ничектер алдавыч кебек кенә тоела, бик тиз үтә. Алда безне озын-озак көзләр көтә. Килешәсездер, нибары өч ай булса да, бөтен ел фасыллары арасында иң озыны көздер кебек тоела. Сәбәбе, бәлки, караңгы, шомлы төннәре, салкын яңгырлы, елак көннәре күп булуга да бәйледер. Бәлки башка сәбәпләр дә бардыр. Әмма ел да беренче кар бик көттереп кенә ява шикелле...

Авыл кешесенең күпчелеге инде малларына җитәрлек терлек азыгын туплады. Өлгеррәкләр өченче кат печән җирләрен бушатты, рулон-рулон печәннәр дә печәнлекләргә урнашты. Күпчелек хуҗалыклар ашлык өләште, салам кайтарып бирде. Соңгыларына, яңгырларга кадәр кайтуы әйбәт булды әле, дип сөенде авылныкылар. Бакча эшләренә караганда малларга кышлык запас туплау авыл кешесе өчен һәрчак мөһим булды. Беренчесен нигәдер, бер елгы эш икенчесенә калмый әле, эшләнер, дип караса да, көзләргә тыныч күңел белән керер өчен печәнлекләрнең шыплап тулган булуы бик мөһим шул. Быелгы кебек күпчелек урыннарны хафага салган корылык елында монысы тагын да зуррак мәшәкатькә әйләнә.

...Менә тагын бер җәй узып китте. Төрлесе булды. Сюрпризлары, көтелмәгән хәлләре дә, сөенечләре, көенечләре дә чиратлашты. Әмма нинди генә булса да, аны үзебезнең гомер китабына теркисе, ил, дөнья тарихына язасы. Ул барыбер кайсыдыр ягы белән кабатланмас, үзгә кебек тоелса да, мондый җәйләр тормышыбызда тагын булачак. Булсын алар. Киләсе елга шушы вакытта тагын: «Ни арада үтте бу җәй?!» – дияргә язсын.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА



100 ЯШЬЛЕК ТАБИБ АСИЯ МАКСЮТОВА:

«АВЫРУЛАРНЫ ТАШЛАП КИТӘРГӘ КЫЕНСЫНДЫМ»

Соклану

Казан медицина институтын «5ле» билгеләренә тәмамлаган Асияне юллама белән Республика тире-венерология диспансерына билгелиләр. Күбесе төрмәдән чыккан ир-атлар яткан бүлеккә килеп эләгә ул. Нинди генә йогышлы авырулар булмый аларда?! Мондый мәхшәрдә бер генә минут та торасы килми кызның. «Кая китсәм дә риза, башка урынга гына җибәрегез», – дип ялына. Тик кая инде ул?! Сугыштан соңгы кырыс еллар бит. Шундук трибунал белән куркыталар.

Хыянәт итми

Шушы көннәрдә 100 яшен тутырган, гомеренең саллы өлешен Республика тире-венерология диспансерында йогышлы авыруларны дәвалауга багышлаган, күп еллар баш табиб булып эшләгән Асия Максютованың хезмәт юлы әнә шулай башлана. Ни кызганыч, бүген аның өченче инсульттан соң кәефе әллә ни түгел. Шуңа күрә күбрәк кызы, табиб-невролог Мәдинә ханым белән сөйләштек.

Институт ишеген Фрунзе шәһәрендә урта мәктәп тәмамлаганнан соң, 1940 елда ачып керә аның әнисе. Сугыш еллары бит, студентларга тизләтелгән режимда белем бирәләр. Бер үк вакытта эшләтәләр дә. 41нең салкын кышында окоп казуларын ул бүген дә оныта алмый. Асия 5 нче шәһәр хастаханәсендә операция бүлегендә шәфкать туташы булып эшли, өч ел ординатурада укый.

Эш урынын кабул итә алмыйча бик өзгәләнгәч, бер тапкыр вакытлыча Сарман районына, тифка каршы көрәш кырына җибәрәләр Асия Вәлиевнаны. Аңа анда башка йогышлы авыруларны да дәваларга туры килә. Тора-бара, үзенең файдалы гамәлләр кылуын аңлап, ияләшеп тә китә. Диспансерда баш табиб вазыйфасына билгеләнгәч, бөтен барлыгын, белемен эшкә җигә. Татарстанда беренче булып матурлык институты ача, сексопатология өлкәсенә дә зур игътибар бирә. Белгечләр әзерләү өчен табибларны Мәскәүгә укырга җибәрә. Шулай итеп, тире-венерология бүлекләре белән бергә һәр районда сексопатолог кабинеты да ачыла. Кыскасы, ул эшләгән чорда бу өлкәгә шактый уңай үзгәрешләр кертелә. Баш табиблыктан киткәч тә, һөнәренә хыянәт итми ул: 75 яшенә кадәр дерматолог-венеролог булып эшли.

– Минем табиблыкка китүем дә үзеннән-үзе хәл ителгән кебек иде. Әниемнән кала, күп кенә туганнарым, барлыгы 10 кеше – медицина хезмәткәрләре, – ди әнисенең эшен дәвам итүче Мәдинә ханым.

Белгән кебек

– Әниемнең әле соңгы елларда да, ягъни өченче тапкыр инсульт булганчы пациентлары бар иде. Ул туганнарыбызны да, дусларын да, танышларын да дәвалады. Аның янына, ахыр чиктә, поликлиникаларга йөреп-йөреп тә файдасы булмагач килделәр. Аннан исә үзенә ярдәм кирәк булды. Быел гыйнвар аенда исә өченче инсульттан соң хәле шактый начарланды. Әмма бернигә карамастан, ул бар җиһанны, кешеләрне яратып яши. Озак яшәвенең сере дә шундадыр, мөгаен. Җирдән беркайчан да аерылмады. 95 яшенә кадәр дачада эшләде, аны гел тәртиптә тотты. Баштарак бөтенебезне яшелчә, җиләк-җимеш белән тәэмин итеп тора иде. Соңрак чәчәкләр үстереп ләззәтләнде. Әнием китап укырга бик ярата, тарих белән кызыксына. Әйләнә-тирәмдә, аның кебек, Россия тарихын белгән кешене белмим. Китапларны китапханәдән алып кайтып бирәм. Ул телевизор карарга яратмый, бөтен мәгълүматны «Аргументы и факты» газетасыннан укый. Сары матбугатны җене сөйми. Күзенә күренсә: «Башка мондыйларны алып кайтма», – дип әрләп тә ала. Махсус хәрби операциядә булган хәлләр белән бик кызыксына. Зиһенле, фикерле ул безнең әни. Операция башланган чорда: «Бу операция берничә елга сузылачак әле», – дигән иде. Ул чакта бу сүзләргә игътибар да итмәгән идек әле...

Асия ханымны котларга Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгыннан, эшеннән килгәннәр, укучылары да булган. «Хәзер инде аның белән бергә эшләгән кешеләр юк, шәкертләре генә калды, – ди бүген тире-венерология диспансерында ветераннар советын җитәкләүче Алсу Микешина. – Интернатурада укыганда бу һөнәргә мине Асия Вәлиевна өйрәтте. Бик таләпчән, әмма гадел иде ул. Вакыты никадәр тыгыз булса да, без алып барган авыру тарихларын тикшерде, төзәтте, аңлатты. Хатын-кыз буларак та һәрьяклап үрнәк булды. Диспансерда аның кебек мөлаем, чибәр кеше юк кебек тоела иде безгә. Остазыбызның кулы җиңел булды. Аның ярдәме белән без күпме авыруларга ярдәм итә алдык».

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ЯЗМАНЫҢ ТУЛЫ ВАРИАНТЫ VATANTAT.RU САЙТЫНДА

Мәрхәмәт

shutterstock.com

Адашканга юл кайда?

Шушы көннәрдә редакциягә ярдәм сорап шалтыраттылар. Казанның Азино микрорайонындагы бер йорт ишегалдына исемен-фамилиясен хәтерләмәүче бер бабай кергән. Кайда яшәгәнен дә белми икән. 80 яшьләр тирәсендәге әлеге бабай турында безгә шул якларда яшәүче ханым сөйләде. «Мондый хәлгә калган кешеләр турында кая хәбәр итәргә?» – дип мөрәҗәгать итте ул безгә. Без әлеге сорауга ачыклык кертергә тырыштык.

Дәрвишләр бистәсендә яшәүче Мөнирә апа Гыйззәтуллина адашып йөргән берничә кешегә өенә кайтырга булышкан.

– Кайда яшәгәнен оныткан кешеләр белән бик сак сөйләшергә кирәк. Безнең бистәдә халык бердәм. Озак еллар монда яшәгәч, өлкәннәрне таныйбыз. Әмма кайчак автобуска утырып адашып килүчеләр була. Андый вакытта ярдәмгә ашыгабыз, – ди гомере буе балаларга белем биргән Мөнирә апа. – Әле менә шушы көннәрдә бер әбинең адашып йөрүен күреп алдык. Сораша торгач, ул барысын да исенә төшерде. Безнең якларга килүе юкка түгел – монда яшь чагында яшәгән булган. Кайчак кәефе төшсә, авыруы кузгалса, бүгенгене онытып, яшьлеккә кайта икән. «Ватсап» төркемнәрендә дә актив безнең халык. Шунда фотосын куябыз да килеп алалар.

Өлкәннәрнең адашуының сәбәбе – аларга игътибар җитмәүдә дигән фикердә Казан шәһәренең Тимерьюлчылар хастаханәсенең гомуми практика табибы Гөлнара Вәлиуллина. «Хәзер кешеләр аралашмый, сөйләшми. Бер йортта яшәп тә, рәхәтләнеп чөкердәшеп чәй эчеп утыручылар кимеде. Өлкәннәргә гел аралашу кирәк», – ди ул.

Кешеләрнең адашып йөрүләренә картлык чире – деменция гаепле, ди табиб. Гөлнара Вәлиуллина әйтүенчә, аларның баш мие зыян күреп, яңа туган бала халәтенә киләләр. Әгәр өйдә салкын яки эссе икән, бу кешеләр урамга чыга. Шул рәвешле үзләренә ошамаган җирдән китә.

– Өлкәннәр чире кемгә кайчан килә бит. Безгә мөрәҗәгать итүчеләр арасында 52 яшьлекләр дә, 80не узганнар да бар. Кемдер 90 яшендә дә аек акыл белән яши. Картлык чиренә бирешүчеләр тиз оныта, тирә-ягындагыларга төрле гаеп ташлый, әйберемне урладың, дияргә, ашатмадың, дип тә әйтергә мөмкин. Алар олы йомышларын да, кечесен дә кая туры килә шунда үти башлый. Инде әйткәнемчә, балага әйләнә. Бу очракта ничек ярдәм итәргә соң? Күпләр олыларны участок терапевтына алып килә. Әмма, кызганыч, без аларны дәвалый алмыйбыз. Бу очракта психиатр яки гериатр кирәк, – ди табиб. – Мондый диагнозлы кеше белән озак вакыт шөгыльләнеп, аның хәлен яхшыртып була. Өлкәннәр гел башын эшләтергә тиеш. Моның өчен укырга, сканвордлар чишәргә кирәк. Бармак очлары белән гел нәрсәдер эшләргә кирәк. Ярмалар аерумы, чигүме, вак төймәләрне тегүме – болар барысы да баштагы нейроннарны эшләтә. Аларны эштән тыймау мөһим.

Картлык чире белән интегүчеләрне махсус интернатларга урнаштырырга, йә булмаса, аларны карарга кеше ялларга кирәк.

Без сөйләшкән берничә ведомствода аңлатуларынча, адашып йөрүче кешеләрне күргән очракта алар белән беренче чиратта тыныч һәм җайлы итеп сөйләшергә, кыска гына сораулар биреп, исемен, кайда яшәвен белешеп карарга кирәк. Бу булышмаса, 112 номерына яки полициягә хәбәр итәргә була. Ә туганнарына исә төп киңәш: өлкәннәрнең кесәләренә аның исем-фамилиясе, адресы, телефон номеры язылган кәгазь салырга кирәк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Үз илемдә – үз телем

И туган тел, и матур тел...

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстандагы төрле милләтләрнең яшәеше, милли гореф-гадәтләре белән таныштыра, «Бер гаилә мисалында туган телне ничек сакларга?» дигән сорауга җавап эзли.

ТАТАР

Алексеевск

БӘХЕТЛЕ ТӘХЕТ

Саф татар авылында: «Туган телне ничек саклап калырга?» – дип сорасаң, мөгаен, гаҗәбрәк тоелыр. Ни дисәң дә, гаиләдә дә, урамда да, мәктәптә дә татарча сөйләшү нигезле әле. Шуңа күрә Алексеевск районының Кыр Шонталысы авылында яшәүче Камаловлар гаиләсенә килеп төшкәч, сорауны башкачарак куйдык. Балаларны татар җанлы итеп үстерү, гореф-гадәтләрне саклап калу өчен нишләргә?

Әкият капчыгы

Сорауны йорт хуҗасы, үзе әйтмешли, бәхетле тәхеттә утыручы 87 яшьлек Шәүкәт абыйга юлласак та, җаваплар төрле тарафтан ишетелә башлады.

– И-и, безнең әти – әкият капчыгы ул. Оныкларны гына түгел, безне дә әкиятләр сөйләп, бишек җырлары көйләп үстерде. Үзе дә уйлап чыгара иде, ахры. Күбесен укыганым да, ишеткәнем дә юк. «Унөченче Әхмәт» дигәне бигрәк тә хәтердә калган, – дип сүз башлады бүген гаиләсе белән Кыр Көрнәлесендә яшәүче кызы Венера. – Бишәүләп тәгәрәшеп үстек, хәзер инде кошлар кебек таралышсак та, барыбызның да балалары әбибабай тәрбиясен тоеп үсте. Әни белән әтинең 15 онигы, 6 оныкчыгы бар хәзер. Үзләренең гаилә корып яши башлауларына – 63 ел.

Әлбәттә инде, төп нигездә калган уллары Айрат, киленнәре Гөлсириннең дүрт баласына мондый бәхет күбрәк тәтегәндер дип уйларга кирәк. Моннан шактый еллар элек бу гаилә белән танышырга туры килгән иде. Ул вакытта оныклар бәләкәй иде әле. Гел күз алдымда тора: кайсы бабасының муенына менеп атланган, кайсы аягына ябышкан, берәү әкият сөйләргә куша, икенчесе уйнарга чакыра, өченчесе... Ул вакытта алар миңа тирәккә кунган кош балалары кебек тоелган иде. Бүген инде зур үскәннәр. Таңсылу югары уку йортын тәмамлап, гаилә корган, Назлыгөл КХТИда укый. Авыл мәктәбендә Ясминә белән Аяз гына калган.

Сүзгә Камаловларның тагын бер кызлары Гөлнур кушылды.

– Тәпи йөреп киткәнче, балаларының да, оныкларының да кулларына гармунмы, курайммы – берәр музыка коралы тоттырды әти. Ватылыр дип тә курыкмады. Җимерелеп төшсә, әрләмәде. Үзе дә уйнады. Безне дә өйрәтте. Хәзер әнә Ясминә белән Аяз Алексеевскига, музыка мәктәбенә йөриләр. Сәхнәдән төшкәннәре юк.

Бу сүзләрне исбатлагандай, гаилә, гөр килеп, «Туган тел» җырын да җырлап алды. Гармунда, баянда уйнаучылар да күп, синтезатор, барабан, гитара да ярдәмгә килде. Бабалары шул арада яшь музыкантларга дәрес бирергә дә өлгерде. Бу җәһәттән зарланып та алды. «Балалар татарча көйләрне уйнарга өйрәнә алмыйлар, чөнки ноталар юк», – диде.

Айрат белән Гөлсирин исә әби-бабаларының хезмәт дәресләренә тукталдылар.

– Әти балаларны инеш буйларына алып төшеп китә. Бергәләп сукмакларны агачлардан чистарталар. Кайчакларда берәр эш тапкан була. «Кырларны таштан чистартып кайтыйк әле», – дип ерак басуларга алып чыгып китә. Шулай итеп табигатьнең матурлыгын күрсәтеп йөри ул аларга. Әниебез Галия аш-су янында мәш килгәндә, балалар аш бүлмәсеннән чыкмый. Барысына да эш табыла. Шуңа күрә өстәлебез төрледән-төрле милли ашлардан сыгылып тора.

Бабам сабаклары

Бабай апам белән мине машина йөртергә дә өйрәтте. Бу өйрәнү «түләүле», бабайның хәйләсенә корылган булып чыкты. Арпа, бодай башаклангач, әйдәгез, басуларны карап кайтыйк дип, ул безне кырга алып бара. Рульгә апам Таңсылу белән алышынып утырабыз. Бераз йөргәч, туктап, арпа-бодай арасында үскән чүп үләннәрне җыябыз. Бабай безгә солычаның зыяны турында сөйли. Уңышны киметә, ди. Безнең кырга баруыбыз үзе бер дәрес була: машина йөртәбез, басуны чүптән арындырабыз, агрономия фәне нигезен өйрәнәбез. Апам машина йөртү курсында укып, таныклык алып кайтты. Казаннан кайтып йөриләр.

Бабай укуны, читкә китүне дә хуплый. Туган авылыңны сагынып кайтыр өчен читкә китеп карарга кирәк, ди. Нигезләрен бетереп киткән кешеләрне бик җәлли. Алар үзләренә саркып тора торган мәңгелек яра ясыйлар, ди.

Назлыгөл КАМАЛОВА

Шул арада Шәүкәт абый Галия апаны ничек итеп урлап кайтуын сөйләп алды. Барысы да рәхәтләнеп көлештеләр. Бүген онытылган, дөресрәге, кулланылудан тукталган гореф-гадәт булса да, үзенә күрә тарих бит инде. Тарих дигәннән, авыл тамырлары да шушы гаиләдә саклана. Шәүкәт абый үзенең сигезенче китабын төгәлләгән. Каләмен кулыннан төшерергә уйламый да. Балалары да, оныклары да ярдәм итә. Бабаларыннан күреп, барысы да язу-сызу эше белән шөгыльләнә. Онигы Назлыгөл «Ватаным Татарстан» газетасы үткәргән «Бу бит безнең авыл» бәйгесендә дә призлы урын яулаган иде.

Оясында ни күрсә...

Очканда шул булыр, дигән гыйбарә бик туры килеп тора Камаловларга.

Гөлсириннең: «Бу нигездә 23 ел килен булып яшим. Әти-әни белән бер тапкыр каршылыкка кереп караганым булмады. Зарланырлык сәбәп тә юк. Айрат та минем әти-әниемә бик хәерхаһлы. Ике якны да бер итеп күрәбез. Аерып карамыйбыз», – дип сөйләгәненә Шәүкәт абый белән Галия апаның кызлары да кушылды.

– Туган нигезгә рәхәтләнеп кайтып йөрибез. Караңгы чырай күргәнебез юк. Әти белән әни ышанычлы кулларда, шуңа шатланып туя алмыйбыз. Гөлсирин аларны бик карый. Авырып китсәләр дә, ярдәменнән ташламый. Рәхмәтебезнең иге-чиге юк. Ходай үзен сәламәтлектән аермасын, – диештеләр.

Эш-гамәлләр дә бергә

Камаловлар гаиләсе авыл, мәктәп тормышыннан аерылгысыз булып яши.

– Безнең өйдә сөйләшүләр ике генә темага була. Берсе – җир, икенчесе – мәктәп, – ди Айрат, уенын-чынын бергә кушып. – Җир – ул әтинеке инде, ул фикер йөрткәнчә, крестьян аннан башка яши алмый, яшәргә дә тиеш түгел. Заманында шактый җир алып калды ул, безне дә, оныкларны да эшкә өйрәтеп үстерде. Туганнарым Венера да, Алсу да, Гөлнур да гаиләләре белән җирдән аерылмаганнар. Шул ук вакытта күбесе укытучы булып эшли. Мәктәптә эшләүчеләр күп безнең нәселдә. Укытучылар җыелса, әти: «Монда мәктәп турында сөйләшәләр икән», – дип китеп барган була.

Айрат үзе дә Шонталы мәктәбендә тарих фәнен укыта. Тарих фәнен укытуга үз карашы бар аның.

– Минемчә, бу фәнне бүген өлкән яшьтәгеләр укытса, әйбәтрәк булыр иде. Чөнки без соңгы вакытта булган барлык үзгәрешләрне дә үз күзләребез белән күрдек. Шул тормышта кайнап яшәдек. Шуңа күрә чагыштыра алабыз, – ди ул.

Айратның тагын бер миссиясе бар: ул – авыл имамы, мәчеткә үзе генә түгел, улы Аяз да йөри. Мәдрәсәгә укырга кергәнен өйдәгеләргә дә соңрак кына әйткән. Авыл хуҗалыгы институтында укыган җиреннән практикага кайткан да китеп тормаган. Дин юлына кереп китүен әнисе ягыннан әби-бабай йогынтысына бәйли.

Гөлсирин исә инде алтынчы ел Шонталы мәктәбендә директор булып эшли, татар теле һәм әдәбиятын укыта. Ул үзен борчыган әйберләр турында да сөйләп алды:

– Авыл нык булып яши дә кебек. Әмма балалар саны күзгә күренеп азая шул. Күп кеше Казанга, Алексеевскига китеп урнаша. Минемчә, мәктәптә уку-тәрбия эшләренең яхшы куелуы кайберәүләрне бу адымнан саклап кала әле. Шуңа күрә бик тә тырышабыз. Балаларны хезмәткә дә өйрәтәбез. Чәчәкләр, үсентеләр үстерәбез. Кишер дә чәчәбез. Аларны саткан акчага техника алабыз. Хәзер бит 9 нчы сыйныфтан соң имтиханнарны татар телендә дә бирергә була. Бөтен фәннәрне татарча укытсак та, ике телдә дә иркен җавап бирерлек итеп өйрәтергә тырышабыз. Районга укуын дәвам итәргә киткән балалар мәктәпне медальгә бетерә. Бик сөенәбез. Ә болай, сүз дә юк, бөтен чаралар, бәйрәмнәр татар телендә үтә.

Директорның сүзләрен раслап дигәндәй, быелгы август киңәшмәсе дә Кыр Шонталысы мәктәбенә зур сөенеч китерә. Мәктәпне яңа 2023–2024 уку елына сыйфатлы итеп әзерләгән өчен беренче урынны яулаганнар, 30 мең сумлык сертификат тапшырганнар. Ә Гөлсирин Сәгыйтовна үзе Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклау һәм үстерү өчен» күкрәк билгесе белән бүләкләнгән. «Рухи кыйммәтләрне саклау һәм ныгыту, борынгы традицияләрне торгызу, шулай ук Россия халыкларының мәдәни мирасын дәвам итү буенча шәхси хезмәтләре өчен» дигән сүзләр бар анда. Бу сүзләр Камаловлар нәселенә атап әйтелгән кебек. Гөлсириннең бу өлкәдә беренче генә бүләге түгел икән. Күптән түгел генә «Туган тел һәм якшәмбе мәктәбе укытучылары арасында үткәрелгән бөтенроссия конкурсының «Профессиягә тугрылык» номинациясендә дә җиңү яулаган ул.

ВИДЕО

Аш бүлмәсенә әни хуҗа

Безнең әни – авылда иң оста пешекче, дип мактый Гөлсирин каенанасын. Мине дә бик күп нәрсәгә өйрәтте. Шулай да аш бүлмәсенә әни хуҗа әле. Без моның шулай булуына бик сөенәбез. Мәшәкатьләр күп булгач, өлгермәс тә идек. Ходай әниебезне сәламәтлектән генә аермасын. Бигрәк тә балалар рәхәтләнә. Аяз мәктәпкә киткәндә заказ биреп китә. Әни бер дә иренеп тормый, әзерләп куя шуларны. Көне буе аяк өстендә йөри торгач, арып та китә торгандыр инде. Кичен без эштән кайткач, үз бүлмәсенә кереп «югала». Без шулай әле һаман да әни тәрбиясендә яшибез. Рәхмәт яусын үзенә.

Сәхифәне Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде. Фото – Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5159 данә
Гомуми тираж – 14047 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 324

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+